**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

**“КАРАЛДЫ”**
МБ җитәкчесе
_______Замалиева И.Х
МБ утырышы беркетмәсе
№1___ 25___август 2016 ел

**“КИЛЕШЕНДЕ”**
«2 нче Алексеевск УГББМ”
МБГБУ директор
урынбасары
________Ягудина Л.Р.
27____ август 2016 ел

**“РАСЛАНДЫ”**
«2 нче Алексеевск УГББМ”
МБГБУ директоры
____________Липлянина Л.Н.
____________номерлы боерыгы
_____ август 2016 ел

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Васильева Антонида Валентиновнаның**
**11 “А” сыйныфы өчен татар теленнән**
**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралды
1____номерлы беркетмә
31____ август 2016 ел

2016-2017 уку елы

**I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.**

**Сыйныф**: 11“А”

**Укытучы**: Васильева А.В

**Уку планы буенча**

**Татар теленнән**: 34 сәг.

**Атнага**: 1 сәг.

Йомгаклау контроль диктант: 1

Сүзлек диктанты: 1

Тест: 2

Изложение: 1

Сочинение: 1

**Дәреслек.** Татарча да яхшы бел. Рус телндә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен татар теле дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Авторы: Р.Р. Нигъмәтуллина. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2011ел.

**Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:**

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында урта гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр:

- татар теленең һәм әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны турында мәгълүмат бирү.
- татар һәм рус телләрендәге аерым грамматик категорияләрнең тәңгәл килү-килмәвен белү;
- татар теленең орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктицион нормаларын белү һәм, аларга нигезләнеп, телдән яки язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;
- аралашу ситуацияләренә бәйле лексик берәмлекләрне, аларның синонимнарын һәм антонимнарын төгәл һәм урынлы куллана белү;
- татар теленең фразеологик берәмлекләрен таный һәм сөйләмдә куллана белү;
- татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белеп, оештыру осталыгына ия булу;
- телнең төп функциясен белү;
- мәктәп курсында өйрәнелгән тел тармакларының система тәшкил итүенә төшенү;
- телдән һәм язмача бирелгән мәгълүматны үзләштерүнең төрле алымнарын файдалану;

• тел – сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен аңлау һәм аларны дөрес куллану. 72
Тыңлап аңлау
• Әңгәмәдәшеңнең татарча сөйләмен тулысынча аңлау, теле-радио тапшыруларын тыңлап өлешчә аңлау.

**Диалогик сөйләм**

• Аралашу процессында төрле репликаларны кулланып, үз фикереңне әңгәмәдәшеңә аңлата белү;
• конкрет проблема буенча әңгәмәдәшең белән бәхәсләшә һәм үз фикереңне дәлилли белү;
• программада тәкъдим ителгән проблема буенча әңгәмәдәшләрең белән иркен аралашуга чыгу.

**Монологик сөйләм**

• Җанлы сөйләмнең төп фикерен атый, аңа үз карашыңны әйтә, яңа мәгълүматны чагыштыра һәм бәяли белү;
• гади һәм кушма җөмләләрне кулланып, тормышта булган хәлләр, ишеткән яңа мәгълүматлар, үзеңне борчыган проблемалар турында хәбәр итә белү;
• программада тәкъдим ителгән әхлакый проблемалар буенча үз фикереңне белдерә белү.

**Уку**

• Уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;
• укыган текстның эчтәлеген логик бөтеннәргә бүлә белү, план төзи белү;

**Язу**

• Укылган әсәр, андагы проблема буенча үз фикереңне язмача җиткерә белү;
• күргән һәм ишеткән турында хикәяләп язу
• рәсми кәгазьләрне (гариза, автобиография, характеристика, резюме) яза белү;
• әхлакый проблемага карата үз фикерләреңне язу, иҗади биремнәр эшләү.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

**Тыңлап аңлау.** Укучыларның җанлы сөйләмне тыңлап аңлау күнекмәләрен камилләштерү; тыңланган мәгълүматка нигезлзнеп, күмәк аралашуда катнашу, җанлы сөйләмнең төп фикерен билгеләү;

**Сөйләү.** Төрле төзелешле җөмлә калыпларын урынлы кулланып һәм аларны интонацон яктан дөрес әйтеп, вакыйгалар, күренешләр, кызыклы фактлар турында хәбәр итү, аларга карата үз мөнәсәбәтеңне һәм фикерләреңне эзлекле итеп белдерүгә ирешү;

**Уку.** Карап чыгу, танышу, эзләнү, өйрәнү, карап чыгу максаты белән уку төрләреннән файдаланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку һәм интернет аша кирәкле мәгълүматны табып уку күнекмәләренә ия булу; укылган текстның эчтәлеген эзлекле итеп сөйләп бирү;

**Язу һәм язма сөйләм.** Тәкъдим ителгән тема буенча чыгыш ясау өчен тезислар язу; аралашу ситуацияләрендә сөйләм үрнәкләреннән һәм гыйбарәләреннән файдалану. Бәйләнешле текстларны рус теленнән татарчага язмача тәрҗемә итү

**11 нче сыйныфны тәмамлаган рус телендә сөйләшүче балалар үзләштерергә тиешле белем –күнекмәләр.**

1. Татар теленең һәм әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны турында мәгълүмат бирү;
2. Татар һәм рус телләрендәге аерым грамматик категорияләрнең тәңгәл килү-килмәвен белү;
3. Татар теленең орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктицион нормаларын белү һәм, аларга нигезләнеп, телдән яки язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;
4. Аралашу ситуацияләренә бәйле лексик берәмлекләрне, аларның синонимнарын һәм антонимнарын төгәл һәм урынлы куллана белү;
5. Татар теленең фразеологик берәмлекләрен таный һәм сөйләмдә куллана белү;

6. Гади һәм кушма җөмләләрнең төрен белү;
7. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белеп, оештыру осталыгына ия булу;
8. Татар һәм рус телләре арасындагы тарихи, мәдәни бәйләнешләр турында белү;
9. Төрле чыгаганклардан ( фәнни-популяр текстлар, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б.) файдаланып, кирәкле мәгълүматны таба һәм башкаларга телдән яки язмаса җиткерә алу;
10. Мәдәниара аралашу ситуацияләрендә әңгәмә кора алу;

## II. Укыту предметының эчтәлеге

| № | Төп темалар | 35 | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Морфология, сүз ясалышы һәм орфографиядән үткәннәрне кабатлау | 1 | Мөстәкыйль сүз төркемнәренә - исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре; бәйләгеч сүз төркемнәренә - бәйлек, теркәгеч; модаль сүз төркемнәрен искә төшерү. |
| 2 | Морфология | 2 | Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр, морфологик анализ. |
| 3 | Синтаксис | 15 | Сүзтезмә, җөмлә турында белешмә бирү, аларны аеру. Җөмләләрне дөрес интонация белән уку, алар азагында тыныш билгеләрен дөрес кую. Тойгылы җөмләләрне башка җөмләләрдә аеру, алардан тиешенчә файдалану. |
| 4 | Җөмләнең модаль кисәкләре | 1 | Эндәш Һәм кереш сүзләрне дөрес интонация белән уку, алардан тиешенчә файдалану, аларга бәйле тыныш билгеләрен дөрес кую |
| 5 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 1 | Тиңдәш кисәкләрне тиешле интонация белән уку, тыныш билгеләрен дөрес кую |
| 6 | Йомгаклау | 3 | Сөйләм төзелешен үзләштерү, морфология белән тыгыз бәйләнешен кабатлау, синтаксисны ныгыту. |

## <u>III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру</u>

| **№** | **Дәрес темасы** | **Укучылар эшчәнлеге төрләре** | **Үткәрү вакыты** |
|---|---|---|---|
| 1 | Кемнән/нәрсәдән тыш? /кала? Грамматик конструкциясе. | Кереш сүз. Әңгәмә. Җөмләләр төзү | 2.09 |
| 2 | Нишли алмас? Нишли алмаслык? Сораулары. **Кереш контоль тест №1** | Контроль дәрес | 9.09 |
| 3 | Укып **бара**, язып **бара** грамматик конструкцияләре. | Карточкалар белән эшләү | 16.09 |
| 4 | Уңай һәм тискәре сыйфатлар. | Сораулар ярдәмендә күршеләр турында диалоглар төзү, җөмләдәге сүзләр тәртибен белү | 23.09 |
| 5 | Дөньяны кемдер пычрата | Фигыльләрнең формаларын кулланып, дөрес итеп җөмләләр төзү, хикәя язу. | 30.09 |
| 6 | Бәйрәмнәр. | Рәсемнәр буенча фикер алышу. | 7.10 |
| 7 | **Тест№2 Тема: Кешеләрчә яшик, кешеләр!** | Контроль дәрес | 14.10 |
| 8 | Хаталар өстендә эш. Һәр гаилә – нәни бер дәүләт | Хаталар өстендә эшләү, бирелгән кагыйдәләргә мисаллар табу, дәлилләү | 21.10 |
| 9 | Чемпионнар командасы. Спорт төрләре. | Яңа сүзләрне кулланышка кертү, диалоглар төзү | 28.10 |
| 10 | Маликовлар гаиләсе | Презентация карау, сораулар буенча эчтәлеген сөйләү | 11.11 |
| 11 | Һәр бала үз ризыгы белән туа. | “Ата – ана даны” ордены турында сөйләү, сүзлекләр белән эшләү | 18.11 |
| 12 | **Изложение“Сәламәт тәндә-сәламәт акыл”** | Контроль дәрес | 25.11 |
| 13 | Хаталар өстендә эш. Нишләгәнгә? Нишләмәгәнгә? Сораулары. | Хаталар өстендә эшләү, бирелгән кагыйдәләргә мисаллар табу, дәлилләү | 2.12 |
| 14 | Нишләгәнгә/нишләмәгәнгә күрә сораулары. | Дәреслек белән эшләү, күнегүләр эшләү | 9.12 |
| 15 | Беркемсез бәбиләр. | Ишетеп аңлау, тәрҗемә эше, ситуатив биремнәр | 16.12 |
| 16 | Ятим балалар темасы буенча кабатлау дәрес | Ятим балалар турында сөйләшү | 23.12 |
| 17 | Гаилә балалар йортлары. | Анының өстәлендә, Казан шәһәрендә сүзтезмәләре белән җөмләләр төзү. | 13.01 |
| 18 | Гади һәм кушма җөмләләр. | Сүзлекләр белән эшләү, гади һәм кушма җөмләләр төзү. | 20.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19 | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр | Таблица, схема буенча эшләү. Җөмләләр төзү. | 27.01 |
| 20 | Байлыгың белән мактанма, кешелегең белән мактан. | Үз фикереңне әйтергә өйрәнү | 3.02 |
| 21 | **Сочинение «Минем дустым»** | Контроль дәрес | 10.02 |
| 22 | Хаталар өстендә эш. Һөнәр сайлау | Хаталар өстендә эшләү, бирелгән кагыйдәләргә мисаллар табу, дәлилләү | 17.02 |
| 23 | Һөнәрләр илендә | Күнегүләр эшләү, бәйләнешле сөйләмгә чыгу. | 24.02 |
| 24 | Киләчәктә кем булырга телисең? | Иҗади биремнәр | 3.03 |
| 25 | Разведчиклар турында. Бәйләнешле сөйләм | Сорауларга җавап бирү, дәреслек буенча эшләү | 10.03 |
| 26 | **Сүзлек диктанты** | Контроль дәрес | 17.03 |
| 27 | Сүз төркемнәренә карата күнегүләр эшләү | Күнегүләр эшләү | 31.03 |
| 28 | Эшсез утыра алмыйм. Монологик сөйләм | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | 7.04 |
| 29 | Ренат Мусин турында. Диалогик сөйләм | Әңгәмә. Тәрҗемә эше. Презентация | 14.04 |
| 30 | Фәнис Яруллин иҗаты | Фәнис Яруллин иҗаты турында сөйләү | 21.04 |
| 31 | **Контроль диктант “Каюм Насыйри-зур галим”** | Контроль дәрес | 28.04 |
| 32 | Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эшләү, бирелгән кагыйдәләргә мисаллар табу, дәлилләү | 5.05 |
| 33 | Йомгаклап кабатлау | Телдән җаваплар, күнегүләр эшләү | 12.05 |
| 34 | Гомумиләштереп кабатлау | Телдән җаваплар, күнегүләр эшләү | 19.05 |

**Пронумеровано, прошнуровано**
**и скреплено печатью**

7 (семь) листов

**учитель татарского языка и литературы**

Васильева А.В.